КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 10 сентябрь г.Казань № 759

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын раслау турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2017 елның 10 июлендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләп чыгару максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативын;

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына карата

инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыймммәте нормативы күрсәткеченә йогынты ясаган башка факторларны исәпкә ала торган төзәтмә кертү (төзәтү) коэффициентларын;

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмаларда койкалар санын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларда алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыймммәте нормативын раслау турында» 2023 ел, 6 сентябрь, 1085 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 10 сентябрь, 759 нчы
карары белән расланды

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы

| Хезмәт күрсәтү исеме | Норматив, койка көненә сум | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру | 903,26 | 904,92 | 906,81 |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 10 сентябрь, 759 нчы
карары белән расланды

2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативына карата инфраструктура белән тәэмин ителүдәге аермалыкларны һәм хезмәт күрсәтү кыйммәте нормативы күрсәткеченә йогынты ясаган башка факторларны исәпкә ала торган төзәтмә кертү (төзәтү) коэффициентлары

| Муниципаль берәмлек исеме | Төзәтмә кертү (төзәтү) коэффициенты | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Азнакай муниципаль районы | 1,580272 | 1,582641 | 1,583542 |
| Әлмәт муниципаль районы | 1,580272 | 1,582641 | 1,583542 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 1,580272 | 1,582641 | 1,583542 |
| Алабуга муниципаль районы | 1,580272 | 1,582641 | 1,583542 |
| Зәй муниципаль районы | 1,580272 | 1,582641 | 1,583542 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 1,623737 | 1,626027 | 1,626837 |
| Лениногорск муниципаль районы | 1,580272 | 1,582641 | 1,583542 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 1,580272 | 1,582641 | 1,583542 |
| Чистай муниципаль районы | 1,580272 | 1,582641 | 1,583542 |
| Яр Чаллы шәһәре | 0,999863 | 1,002026 | 1,003155 |
| Казан шәһәре | 0,999954 | 1,002124 | 1,003253 |

_______________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 10 сентябрь, 759 нчы
карары белән расланды

2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына алкогольдән, наркотиктан яисә башка токсик матдәләрдән исерек хәлендәге затларга ярдәм күрсәтү өчен махсуслаштырылган оешмаларда койкалар саны

| Муниципаль берәмлек исеме | Койкалар саны | | |
|---|---|---|---|
| | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Азнакай муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Әлмәт муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Бөгелмә муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Алабуга муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Зәй муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Зеленодольск муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Лениногорск муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Түбән Кама муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Чистай муниципаль районы | 10 | 10 | 10 |
| Яр Чаллы шәһәре | 20 | 20 | 20 |
| Казан шәһәре | 40 | 40 | 40 |